ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 10 февралендә
кабул ителде

## 1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга сала.

## 2 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә хокукый җайга салу**

Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә хокукый җайга салу «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы), башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 3 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын кабул итү;

2) җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм башкаруны тикшереп тору;

3) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итү;

2) федераль дәүләт хакимияте органы белән берлектә Татарстан Республикасы территориясендәге җир асты байлыклары дәүләт фонды белән эш итү, моңа бары тик Россия Федерациясе карамагында гына булган җир асты байлыклары кишәрлекләре керми;

3) Россия Федерациясе җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, минерал-чимал базасын үстерү һәм үзләштерү буенча дәүләт программаларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

4) минерал-чимал базасын үстерү һәм алардан файдалану буенча территориаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру;

5) җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, минерал-чимал базасын торгызу һәм җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану буенча Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

6) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүне гамәлгә ашыручы башкарма органын (алга таба – Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы) билгеләү;

7) иясе Татарстан Республикасы булган җир асты байлыклары турында геологик мәгълүматтан файдалану тәртибен һәм шартларын билгеләү;

8) җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы белән берлектә гомумтаралган файдалы казылмаларга карый торган файдалы казылмаларның республика исемлеген әзерләү һәм раслау;

9) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән (алга таба – җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре) файдалану хокукын әлеге Законның 7 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында каралган нигезләр буенча бирү тәртибен билгеләү;

10) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яисә берләштерелгән лицензия буенча аларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыру өчен, эчәргә яраклы су һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү (алга таба – эчәргә яраклы су белән тәэмин итү) яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты суларын

чыгару өчен, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда файдалануга бирү тәртибен билгеләү;

11) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен билгеләү;

12) «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы белән үзләренә бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләре чикләрендә файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны яисә берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм чыгаруны, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләүне яисә берләштерелгән лицензия буенча авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләүне, шундый файдалы казылмаларны разведкалауны һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан үзләренең җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен гомумтаралган файдалы казылмаларны расланган техник проект нигезендә чыгару тәртибен билгеләү;

13) җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләрен арендага алучыларның үз ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләре чикләрендәге гомумтаралган файдалы казылмалардан, җир асты суларыннан файдалану, шулай ук җир асты корылмаларын төзү тәртибен билгеләү;

14) коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында әлеге ширкәтләр тарафыннан җир асты суларын чыгару тәртибен билгеләү;

15) минералогик, палеонтологик һәм башка геологик коллекцион материаллар җыю өчен җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы бирү турында җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы белән килештерелгән карарлар кабул итү;

16) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, шулай ук аларга үзгәрешләр кертү тәртибен билгеләү;

17) Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның хокукларын һәм гражданнарның мәнфәгатьләрен яклау, җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре буенча бәхәсләрне хәл итү;

18) Россия Федерациясе Конституциясендә һәм федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы исеменнән җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда продукция бүлешү турындагы килешүләрдә катнашу;

19) файдалы казылмалар чыганакларыннан файдалану шартларын билгеләүдә катнашу;

20) региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау;

21) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

5 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы вәкаләтләре**

Җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын кабул итү;

2) җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы белән килештереп, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеген әзерләү һәм раслау;

3) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү турында һәм аукцион комиссияләренең составы хакында карарлар кабул итү;

4) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкаруга «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә дәүләт контрактлары төзү;

5) җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органына яисә аның территориаль органына җир асты байлыклары кишәрлекләрен җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен, файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен, берләштерелгән лицензия буенча гамәлгә ашырыла торган җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яисә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертү турында, җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар үткәрү шартлары һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләр шартлары турында тәкъдимнәр кертү;

6) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирү;

7) җир асты байлыкларыннан файдалануның «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 6 статьясында каралган төрләре буенча җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану шартларын әзерләү;

8) гомумтаралган файдалы казылмалар чыганакларын ачу фактын билгеләү буенча составына җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы вәкилләре керә торган комиссия төзү;

9) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштергәндә яисә яңадан рәсмиләштергәндә җибәрелгән техник хаталарны (сүзне бозып язу, ялгыш басу, грамматик яисә арифметик хаталарны яисә шундый башка хаталарны) төзәтү;

10) җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләү ставкасының конкрет күләмен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга тиешле тәртиптә лицензия бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларының һәр кишәрлеге буенча аерым билгеләү;

11) «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының $10^1$ статьясындагы беренче өлешенең 4 пунктында күрсәтелгән максатларда җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукы бирү турында гаризаларны карау өчен җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы тарафыннан төзелә торган комиссия эшендә катнашу;

12) «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының $23^2$ статьясының өченче өлешендә каралган авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләүгә проект документациясен, шулай ук күрсәтелгән проект документациясенә кертелә торган үзгәрешләрне килештерү буенча җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы тарафыннан төзелә торган комиссия эшендә катнашу;

13) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын туктату, шул исәптән вакытыннан алда туктату, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын чикләү тәртибен билгеләү;

14) җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын гамәлгә ашыруны туктатып тору һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын чикләү буенча комиссия төзү;

15) Татарстан Республикасының геологик мәгълүмат фондын булдыру һәм алып бару;

16) файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләренең һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләрнең дәүләт реестрын алып бару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләргә карата белешмәләр бирү;

17) файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасында катнашу;

18) файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмый торган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы үткәрү;

19) гомумтаралган файдалы казылмалар запасларының республика балансын һәм аларның чыганаклары һәм чагылышлары республика кадастрын төзү һәм алып бару, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган корылмалар төзү өчен файдаланыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләрен исәпкә алу;

20) гомумтаралган файдалы казылмалар чыганакларын эшкәртүнең техник проектларын, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын, радиоактив калдыкларны, I – V класслы хәвефлелектәге җитештерү һәм куллану калдыкларын күмү өчен җир асты корылмаларыннан, углеводород чималын саклау корылмаларыннан тыш (алга таба – файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмалары), төзүнең һәм эксплуатацияләүнең техник проектларын, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшләнмәләрен, бораулау скважиналарын һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларны бетерү һәм консервацияләүнең техник проектларын килештерү;

21) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән очракларда, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшләре кишәрлеген бүлеп бирүнең төгәлләштерелгән чикләрен тикшергән документларны (тау эшләре кишәрлеге акты һәм график кушымталар) рәсмиләштерү;

22) региональ дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;

23) законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

6 статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре**

1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә түбәндәгеләр керә:

1) гомумтаралган файдалы казылмалар булган җир асты байлыклары кишәрлекләре;

2) файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү һәм аларның яраклы булуын бәяләү өчен файдаланыла торган һәм (яисә) файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләре;

3) эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмаган, шулай ук коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты сулары булган җир асты байлыклары кишәрлекләре.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеген әзерләү һәм раслау, җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы

белән килештереп, Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү нигезләре**

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органының Татарстан Республикасы законнары нигезендә түбәндәгеләр турында кабул ителгән карары:

а) файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү һәм аларның яраклы булуын бәяләү өчен һәм (яисә) файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында;

б) гомумтаралган файдалы казылмалар чыганакларын эзләү һәм бәяләү өчен гомумтаралган файдалы казылмалар чыганагы булган һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен үткәргән җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ачык чыганакның табылу факты билгеләнгәндә, мондый җир асты байлыклары кишәрлегеннән ачык чыганактагы гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен файдалану хокукын бирү турында, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән дәүләт контракты нигезендә җир асты байлыкларының бу кишәрлеген геологик өйрәнү гамәлгә ашырылган очракта, җир асты байлыклары кишәрлеге моңа керми;

в) файдалану хокукы вакытыннан алда туктатылган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә юридик зат (оператор) эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән кыска вакытлы (бер елга кадәр) файдалану хокукын бирү турында;

г) гомумтаралган файдалы казылмалар чыганакларын эзләү һәм бәяләү максатларында җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында;

д) җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару өчен яисә җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны разведкалау һәм чыгару максатларында җир асты байлыкларын геологик өйрәнү өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында;

е) «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон яисә «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән, гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен башкаруга граждан-хокук шартнамәләренә таянып гамәлгә ашырыла торган шушы эшләрне башкару максатларында кирәкле гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен гомумтаралган файдалы казылмалары булган һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлегенә кертелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә бирү турында;

ж) коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яисә) коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәтләрен эчәргә яраклы су белән тәэмин итү яисә техник су белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты суларын чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында;

2) Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан төзелә торган аукцион комиссиясенең файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен яисә берләштерелгән лицензия буенча җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылмалары разведкалау һәм чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион нәтиҗәләре буенча бирү турында, ә «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының $13^1$ статьясындагы сигезенче өлешендә каралган очракта, әлеге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын гаризасы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы таләпләренә һәм игълан ителгән аукцион шартларына туры килә торган затка яки аукционның бердәнбер катнашучысына бирү турында карары;

3) Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органының җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итүнең федераль органы яисә аның территориаль органы белән килештерелгән һәм минералогик, палеонтологик һәм башка геологик коллекцион материаллар җыю өчен кабул ителгән карары;

4) продукция бүлешү турында «Продукция бүлешү турында килешүләр хакында» 1995 елның 30 декабрендәге 225-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән килешү;

5) җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкаруга җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенә карата «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан төзелгән дәүләт контракты.

8 статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион үткәрмичә бирү**

1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән әлеге Законның 7 статьясындагы 1, 3 – 5 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча файдалану хокукы аукцион үткәрмичә генә бирелә.

2. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын әлеге Законның 7 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез буенча бирү җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алуга Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органына мондый хокук алу өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр кушымта итеп тапшырылган гаризаны (алга таба – гариза) карау нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

3. Гариза һәм аңа кушымта итеп тапшырыла торган документлар һәм белешмәләр алынганнан соң 20 эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы мөрәҗәгать итүчегә әлеге Законның 7 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез буенча җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында яисә гаризаны кабул итүдән баш тарту хакында карар кабул итә, гариза бирүчегә бу хакта тиешле карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә хәбәр итә.

4. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын әлеге Законның 7 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез буенча бирү тәртибе, гариза формасы, гаризага кушымта итеп бирелә торган документларның һәм белешмәләрнең тулы исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын әлеге Законның 7 статьясындагы 3 – 5 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча бирү «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

9 статья. **Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын аукцион нәтиҗәләре буенча бирү**

1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән әлеге Законның 7 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез буенча файдалану хокукы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә үткәрелә торган аукцион нәтиҗәләре буенча бирелә.

2. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына аукцион үткәрү турында, тиешле аукцион комиссиясе составы хакында карар Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан кабул ителә.

3. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын әлеге Законның 7 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез буенча бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10 статья. **Региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге)**

1. Региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата региональ дәүләт геология контроленең (күзәтчелегенең) предметы җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законында, Россия Федерациясе Су кодексында (җир асты су объектларын саклауга таләпләр өлешендә), Россия Федерациясе Салым кодексында (файдалы казылмалар һәм җир асты су объектларын чыгарганда югалту нормативлары өлешендә) һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу буенча вәкаләтләр чикләрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләрдә һәм күрсәтелгән норматив хокукый актларда каралган башка рөхсәт документларында булган таләпләрнең оешмалар һәм гражданнар тарафыннан үтәлешеннән гыйбарәт.

3. Үтәлеше региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) кысаларында бәяләнә торган мәҗбүри таләпләр кертелгән рөхсәт документларының исемлеге региональ дәүләт геология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәдә күрсәтелә.

4. Региональ дәүләт геология контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.

11 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12);

2) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 1999 елның 6 декабрендәге

2486 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2);

3) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2001 елның 21 ноябрендәге 1193 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 12);

4) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2004 елның 23 июлендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7);

5) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 8 апрелендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш);

6) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 20 мартындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 3);

7) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 22 октябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 9 – 10);

8) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1);

9) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2012 елның 14 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш);

10) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 28 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш);

11) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 20 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 1 – 2);

12) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 11 апрелендәге 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 4);

13) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 14 маендагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 5);

14) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 15 декабрендәге 119-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 12 (II өлеш);

15) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 2 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 7 (I өлеш);

16) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 3);

17) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 12 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш);

18) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 16 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш);

19) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 30 ноябрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 92 (I өлеш);

20) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законының $35^{8.2}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 17 июлендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш);

21) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 4 июлендәге 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 51 (I өлеш);

22) «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 11 декабрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 94 (I өлеш);

23) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 11 декабрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 93 (I өлеш).

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 25 февраль
№ 5-ТРЗ